**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге советы КАРАРЫ**

**2019 елның 26 ноябре** **138 номерлы**

**"Җир салымы турында" 2017 елның 14 ноябрендә кабул ителгән 69 номерлы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге Советы КАРАР чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге Советының 2017 елның 14 ноябрендә кабул ителгән 69 номерлы «Җир салымы турында " карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 статьяның 2 пунктында «(индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш) эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланыла торган” сүзләрен өстәргә

5 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

6 статьяга түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Сайлап алынган җир участогы турында хәбәрнамә салым органына дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша тапшырылырга мөмкин».

2. Әлеге карарның 1 пунктындагы икенче абзацы 2020 елның 1 гыйнварыннан, әмма әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән бер айдан да соңга калмыйча үз көченә керә.

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

ТР, Кама Тамагы районы, Тәмте авылы, 2 нче Октябрь урамы, 50 нче йорт ( мәдәният йорты бинасы)

ТР, Кама Тамагы районы, Тәмте авылы, Октябрь урамы, 65 йорт ( АЖ бинасы)

шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Тәмте авыл җирлеге башлыгы,
Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Тәмте авыл җирлеге Советы рәисе И. А. Зиновьев